ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^{1}$ статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы медицина оешмаларын дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары, иммунобиологик препаратлар белән тәэмин итү, медицина техникасын ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү, шулай ук даруларны, медицина әйберләрен, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктларын түләүсез алу хокукына ия булган гражданнарны шулар белән тәэмин итү максатларында «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә «Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак түбәндәгеләрне тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 июнь
№ 43-ТРЗ